СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.06.2020 с. Сарманово № 242

Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата хезмәте турында» нигезләмәнең 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы карарның 16 нчы кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге (редакциядә 21.05.2020 елдан) 573 номерлы нигезләмә, Татарстан Республикасы Югары Судының 2020 елның 22 маендагы карары, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата хезмәте турында» нигезләмәнең 2018 елның 13 августындагы130 номерлы карарның 16 нчы кушымтасын гамәлдә түгел дип таныргa.

2. Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата хезмәте турында» нигезләмәнең 2018 нче елның 13 августындагы 130 номерлы карарның 16 нчы кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин

Сарман муниципаль районы Советы карарына кушымта
22.06.2020 ел №242

Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата хезмәте турында» нигезләмәнең 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы карарның 16 нчы кушымтасы

**Дәүләт серен тәшкил итүче һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәдә эш стажы өчен дәүләт серен (махсус өлешләрне) тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү тәртибе**

1. Муниципаль хезмәткәрләргә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен хезмәт хакына айлык процент өстәп түләү түләнә, ә дәүләт серен (махсус өлешләрне) саклау буенча структур бүлекчә хезмәткәрләренә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык процентлы өстәмәне өстәмә рәвештә күрсәтелгән структур бүлекчәдә эш стажына карата процент өстәмәсе түләнә.

| Айлык процент өстәмә | %ларда |
|---|---|
| «аеруча мөһим» булган серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 50-75 |
| «бөтенләй яшерен» серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 30-50 |
| Рөхсәт рәсмиләштергәндә «яшерен» серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | |
| тикшерү чаралары үткәрүе белән | 10-15 |
| тикшерү чаралары үткәрмичә | 5-10 |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен: | |
| 1 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан һәм артыграк | 20 |